**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 10 октябрендәге 4290 номерлы карары**

**2024 елның 4 ноябрендә Казан шәһәрендә**
**хач йөрешен үткәрүдә ярдәм**
**күрсәтү турында**

Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе идарәчесе Казан һәм Татарстан митрополиты Кириллның 2024 елның 4 ноябрендә Благовещение соборыннан Крестовоздвижение чиркәвенә кадәр могҗизалы Казан Изге Ана иконасы белән хач йөрешен үткәрүдә ярдәм күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң:

**1. Карар бирәм:**

1.1. транспорт чаралары хәрәкәтенә һәм туктап торуына чикләү кертергә:

1.1.1. 2024 елның 4 ноябрендә 07.00 сәгатьтән, хач йөреше автомобиль юлы буйлап узганнан соң хәрәкәт ачыла торган итеп, түбәндәге юллар буенча:

- Кремль урамы, Чернышевский урамыннан алып Беренче Май мәйданына кадәрге участокта;
- Профсоюз урамы, Чернышевский урамыннан алып Меңьеллык мәйданына кадәрге участокта;
- Беренче Май мәйданыннан төшү юлы, Кремль урамыннан алып Профсоюз урамына кадәрге участокта;
- Бауман урамы, Профсоюз урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;
- Меңьеллык мәйданыннан Батурин урамына төшү юлында;
- Батурин урамыннан Кремль транспорт дамбасына төшү юлында;
- Батурин урамы, Кремль транспорт дамбасыннан алып Дзержинский урамына кадәрге участокта;
- К.Маркс урамы, Лобачевский урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;

- Япеев урамы, Дзержинский урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта (кирәк булган очракта);

- Миславский урамы, К.Маркс урамыннан алып Дзержинский урамына кадәрге участокта;

1.1.2. 2024 елның 4 ноябрендә 07.00 сәгатьтән 09.30 сәгатькә кадәр Большая Красная урамының машиналар йөри торган юлы буенча, Япеев урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;

1.1.3. 2024 елның 3 ноябрендә 20.00 сәгатьтән 2024 елның 4 ноябрендә 09.30 сәгатькә кадәр Миславский урамының машиналар йөри торган юлы буенча, К.Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта (транспорт куюны тыеп);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) хач йөреше маршруты буенча юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын каплау һәм ачу, сүтү буенча эшләр башкаруны, транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны билгеләнгән вакытта Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

1.3. «Шәһәр парковка киңлеген оештыручы» муниципаль казна учреждениесенә (И.Б.Тихонов), кертелә торган чикләүләрне исәпкә алып, муниципаль парковкалар өчен түләүне контрольдә тоту буенча автомобиль хәрәкәте маршрутын үзгәртергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә килү юлларын һәм транспорт кую урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, юлларны йөк техникасы белән ябу эшен оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга,

әлеге карар нигезендә Казан шәһәренең урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм боеру-җайга салу гамәлләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (В.С.Филатов) хач йөрешендә катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) массакүләм мәгълүмат чаралары аша Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертелүе турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**